КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 13 февраль г.Казань № 100

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 апрель, 161 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 апрель, 161 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 28 декабрь, 628 нче, 2006 ел, 22 март, 117 нче, 2006 ел, 5 июль, 341 нче, 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы, 2007 ел, 21 март, 98 нче, 2007 ел, 17 декабрь, 726 нчы, 2008 ел, 5 июнь, 373 нче, 2008 ел, 14 ноябрь, 806 нчы, 2008 ел, 18 декабрь, 899 нчы, 2009 ел, 20 апрель, 239 нчы, 2009 ел, 28 декабрь, 897 нче, 2010 ел, 30 декабрь, 1135 нче, 2011 ел, 4 август, 633 нче, 2012 ел, 6 апрель, 279 нчы, 2012 ел, 17 сентябрь, 772 нче, 2013 ел, 19 гыйнвар, 22 нче, 2013 ел, 26 декабрь, 1062 нче, 2013 ел, 28 декабрь, 1074 нче, 2014 ел, 26 декабрь, 1036 нчы, 2015 ел, 30 ноябрь, 904 нче, 2016 ел, 27 декабрь, 1010 нчы, 2017 ел, 31 октябрь, 829 нчы, 2017 ел, 6 ноябрь, 844 нче, 2018 ел, 10 август, 655 нче, 2018 ел, 10 декабрь, 1108 нче, 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче, 2019 ел, 6 декабрь, 1111 нче, 2020 ел, 4 ноябрь, 990 нчы, 2024 ел, 25 июнь, 462 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә

алып) расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенә, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 07 апрель, 161 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 ел, 13 февраль, 100 нче карары редакциясендә)

Татарстан Республикасында айлык бердәм социаль юл билетын һәм айлык бердәм балалар социаль юл билетын бирү тәртибе

1. Бердәм айлык социаль юл йөрү билеты (алга таба – юл билеты) һәм бердәм айлык балалар социаль юл йөрү билеты (алга таба – балалар юл билеты) социаль ярдәм чаралары «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон, «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы Федераль закон, «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федераль закон, «Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында» 2012 елның 20 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль хезмәтләре дәүләт системасы хезмәткәрләренең гомуми файдаланудагы транспортта йөрүе турында» 2005 ел, 15 июнь, 271 нче карары белән каралган гражданнар категорияләре өчен кертелә. https://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=RLAW363&n=192581

2. Юл билетына һәм балалар юл билетына хуҗасының исеме язылган була, чикләнмәгән санда транзакцияләр рөхсәт ителгән электрон карта рәвешендә башкарыла.

Транзакция – сәфәрне кылу фактын берсүзсез раслый торган юл билеты, балалар юл билеты кулланып, сәфәрне теркәү операциясе.

Автоматлаштырылган система операторы – транспорт оешмаларына һәм шәһәр җәмәгать транспортының барлык төрләрендә һәм шәһәр яны автомобиль транспортында йөрү өчен түләүнең автоматлаштырылган системасына хезмәт

күрсәтүче юридик зат.

3. Юл билеты һәм балалар юл билеты, әлеге Тәртипнең 4 пунктындагы «т» пунктчасында күрсәтелгән гражданнардан тыш, әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләре өчен шәһәр җәмәгать транспортының барлык төрләрендә һәм шәһәр яны автомобиль транспортында йөрү хокукын бирә.

Әлеге Тәртипнең 4 пунктындагы «т» пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өчен юл билеты муниципаль берәмлек чикләрендә шәһәр җәмәгать транспортының барлык төрләрендә һәм шәһәр яны автомобиль транспортында йөрү хокукын бирә.

Юл билетының һәм балалар юл билетының гамәлдә булуы шәһәрара автобус маршрутларына кагылмый.

Әлеге Тәртипнең 4 пунктындагы «м» пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өчен юл билеты шәһәр җәмәгать транспортының барлык төрләрендә һәм шәһәр яны автомобиль транспортында йөрү хокукын озатып йөрүче зат I төркем (хезмәт эшчәнлегенә сәләте чикләнгән III төркем) инвалиды яисә инвалид бала белән бергә барганда гына бирә.

4. Юл билеты һәм балалар юл билеты түбәндәге категория гражданнарга бирелә:

юл билеты:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;

б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар;

в) хәрби хәрәкәтләр ветераннары;

г) 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 3 сентябренә кадәрге чорда кимендә алты ай гамәлдәге армия составына кермәгән хәрби частьларда, учреждениеләрдә, хәрби-укыту йортларында хәрби хезмәт узган хәрби хезмәткәрләр, шулай ук күрсәтелгән чорда хезмәт иткән өчен СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән хәрби хезмәткәрләр;

д) «Блокададагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән затлар;

е) Бөек Ватан сугышы чорында һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, һава һөҗүменә каршы җирле оборона объектларында, оборона корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм хәрәкәт бара торган фронтлар тылы, хәрәкәт бара торган флотларның операция зоналары чикләрендә башка хәрби объектлар төзүдә, тимер юл һәм автомобиль юлларының фронт яны участокларында эшләгән затлар; транспорт флотының Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләр портларында мәҗбүри тоткарланган суднолар экипажлары әгъзалары;

ж) һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышы инвалидларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарының гаилә әгъзалары, һава һөҗүменә каршы җирле оборона объектларын һәм авария командаларын үзсаклау төркемнәренең шәхси составына кергән Бөек Ватан сугышында һәлак булган затларның гаилә әгъзалары, шулай ук Ленинград шәһәре госпитальләренең һәм хастаханәләренең һәлак булган хезмәткәрләренең гаилә әгъзалары;

з) «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләнгән яисә 2018 елның 31 декабренә торышы

буенча күрсәтелгән федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган хезмәт ветераннары, 60 һәм 55 яшькә җиткәннән соң (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) башка нигезләр буенча пенсия алучы яки эш (хезмәт) өчен гомерлек матди тәэминат алучы хезмәт ветераннары;

и) 1941 елның 22 июненнән алып 1945 елның 9 маена кадәр чорда тылда кимендә алты ай, СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү чорыннан тыш, эшләгән затлар; Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән затлар;

к) реабилитацияләнгән затлар һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затлар;

л) Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары, 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Течу елгасына радиоактив калдыкларны ташлану аркасында радиация йогынтысына дучар булган затлар, аерым куркыныч бүлекчәләрдәге гражданнар;

м) I төркем (хезмәт эшчәнлегенә сәләте чикләнгән III дәрәҗә) инвалидларын яисә инвалид балаларны озата баручы затлар (һәр I төркем (хезмәт эшчәнлегенә сәләте чикләнгән III дәрәҗә) инвалидына яисә инвалид балага иң күбе бер озата баручы);

н) «СССРның мактаулы доноры», «Россиянең мактаулы доноры» билгеләре белән бүләкләнгән затлар;

о) инвалидлар;

п) Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү дәүләт системасы хезмәткәрләре;

р) Икенче бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союздашлары тарафыннан төзелгән концлагерьларның, гетто, башка мәҗбүри тоту урыннарның балигъ булмаган элеккеге тоткыннары;

с) «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, картлык буенча яисә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле стажы булган, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яисә 2018 елның 31 декабренә торышы буенча күрсәтелгән федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган затлар, шулай ук «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, 60 һәм 55 яшькә җиткәннән соң (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) пенсияләрне башка нигезләр буенча яисә эш (хезмәт) өчен гомерле матди тәэминат алучылар;

т) пенсионерлар, 60 һәм 55 яшькә җиткән (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) гражданнар, 2018 елның 31 декабренә торышы буенча “Иминият пенсияләре турында”, “Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында” һәм “Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында” федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүче, әмма 60 һәм 55 яшькә җитмәгән (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар), әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “а - с” пунктчаларында

күрсәтелгән гражданнар категорияләренә карамый торган гражданнар;

балалар юл билеты:

у) инвалид балалар;

ф) гаилә составында өч һәм аннан күбрәк балалары (тәрбиягә алган балаларны кертеп) булган гражданнар балалары, аларның олы баласына 18 яшь яки, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә белем алу шарты белән гомуми белем бирү оешмасында аны тәмамлаганга кадәр белем алып, 23 яшь тулганга кадәр, әмма аңа иң күбе 23 яшь тулганга кадәр;

х) мәгариф учрежденияләрендә белем алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар.

5. Юл билеты һәм балалар юл билеты гражданны әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән категориягә кертүне раслый торган документ күрсәтелгәндә бирелә.

I төркем (хезмәт эшчәнлегенә сәләте чикләнгән III дәрәҗә) инвалидларын яисә инвалид балаларны озата баручы гражданнарга юл билеты инвалидның документлары яисә инвалид баланың документларын күрсәтеп сатып алына.

6. Җәмәгать транспортында юл билетыннан файдаланып йөргәндә граждан бер үк вакытта аның юл билетыннан файдалану хокукын раслаучы документны яки тиешле документларда булган «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм мәгълүмат алмашуның күпфункцияле сервисын булдыру турында» 2025 елның 24 июнендәге 156-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән мәгълүмат алмашуның күпфункцияле сервисыннан файдаланып бирелгән белешмәләрне күрсәтергә тиеш.

Әгәр мондый документтан белешмәләр мәгълүмат алмашуның күпфункцияле сервисыннан файдаланып бирелгән булса, юл билетыннан файдалану хокукын раслаучы документны тапшыруны таләп итү рөхсәт ителми.

7. Транспортка юл билетын яисә балалар юл билетына акча салмаган әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән гражданнар җәмәгать транспортында барган өчен гамәлдәге тарифлар буенча гомуми нигезләрдә түлиләр.

8. Юл билетларына һәм балалар юл билетларына акча салу срогы - алар гамәлдә була торган айның 10 числосына кадәр.